**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 01 » 03 2024 № 48

Аксубаево

Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының
«2024 елның беренче яртыеллыгына Халык өчен торак
хезмәтләренә тарифлар турында» 04.12.2023 № 358
карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты

Карар итә:

1. Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «2024 елның беренче яртыеллыгына Халык өчен торак хезмәтләренә тарифлар турында» 04.12.2023 № 358 карарына 2 нче кушымтаны яңа кушымта редакциясендә бәян итеп үзгәреш кертергә.

2.Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз көчен җәелдерә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга http://aksubayevo.tatarstan.ru һәм хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе С.Ю.Зайцев

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты
«01» 03 2024 № 48
карарына кушымта

**МУНИЦИПАЛЬ ТОРАК ФОНДЫНЫҢ ТОРАК УРЫННАРЫН АРЕНДАЛАУ КИЛЕШҮЛӘРЕ БУЕНЧА ТОРАК УРЫННАРНЫ ЯЛЛАУЧЫЛАР ӨЧЕН ТОРАК БИНАДАН ФАЙДАЛАНУ ӨЧЕН БАЗА СТАВКАСЫ (АРЕНДА ӨЧЕН БАЗА СТАВКАСЫ)**

| Түләү исеме | Хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге | Хезмәтне үлчәү берәмлеге өчен төп ставка (рубльдә) |
|---|---|---|
| | | 2024 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 30 июненә кадәр |
| 1 | 2 | 3 |
| Төп яллау ставкасы | аена торак бинаның гомуми мәйданының квадрат метры | 7,70 |